# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**№ 2** **«21» ноябрь 2020 ел**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Ютазы муниципаль районы Әпсәләм авыл җирлегенең тимер юл разъезды бистәсендә Тынычлык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 15 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 8 кеше катнашты, бу барлык исемлектәге халыкның 53,3 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 7 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе торак пунктында халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип исәпләргә.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешегә 400,00 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Ютазы муниципаль районы Әпсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендә Тынычлык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) - карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында

интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб - адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева